КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.12.2021 г.Казань № 296-П

Татарстан Республикасының Баулы муниципаль районында урнашкан «Иске Чүте стоянкасы» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясенең чикләрен һәм файдалану режимын раслау турында

"Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында" 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында" 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 12 июлендәге 565 номерлы "Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты мәсьәләләре" карары нигезендә боерам:

1. Бу боерыкка 1 кушымта нигезендә, Татарстан Республикасының Баулы муниципаль районында урнашкан «Иске Чүте стоянкасы» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясенең чикләрен расларга (бастырып чыгарылырга тиеш түгел).

2. Бу боерыкка 2 кушымта нигезендә, Татарстан Республикасының Баулы муниципаль районында урнашкан «Иске Чүте стоянкасы» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясеннән файдалану режимын расларга.

3. Мәдәни мирас объектларын исәпкә алу һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге бүлегенә ачыкланган мәдәни мирас объектының чикләре турындагы мәгълүматларны Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрына кертүне тәэмин итәргә.

4. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Комитет рәисе урынбасары Н.В.Прохоровага йөкләргә.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы мәдәни
мирас объектларын саклау
комитетының «02» 12.2021 елның
296-П боерыгына 2 кушымта

Татарстан Республикасының Баулы муницапаль районында урнашкан «Иске Чүте стоянкасы» ачыкланган мәдәни (археологик) мирас объекты территориясеннән файдалану режимы

Чикләрендә ачыкланган археологик мирас объекты урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым режимы "Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында" 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - 73-ФЗ номерлы Федераль закон), җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләре, ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү, шулай ук гражданнарның күрсәтелгән объектка керүен тәэмин итү шартларында урманнардан һәм башка эшләрдән файдалану буенча эшләр башкару мөмкинлеген күздә тота.

Ачыкланган археологик мирас объекты урнашкан су объектын яисә аның өлешен куллануның аерым режимы ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү, шулай ук 73-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә гражданнарның әлеге объектка керүен һәм археологик кыр эшләрен уздыруны тәэмин итү шартларында Россия Федерациясе Су кодексында билгеләнгән эшләрне башкару мөмкинлеген күздә тота.